ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН! СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ- СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО - ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №145 (7318) | 3 декабрь, 1991 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## КЫЗУ ЭШ КАЙНЫЙ

«Игенче» колхозының машина-тракторлар паркында бу көннәрдә эш аеруча киеренке. Механизаторлар язгы кыр эшләрендә һәм урып-җыю чорында хезмәт иткән авыл хуҗалыгы машиналарын көйләү белән мәшгульләр. Ни әйтсәң дә, киләсе ел уңышы турында алдан ук чаралар күрүнең зарурилыгын һәммәсе дә яхшы аңлый.

Бүген биредә 4 группа хезмәт куя. Вәли Сөләйманов, Равил Хисмәтов, Хәлим Хәсәншин культиваторларны, пенсионер Сәмикъ Сафиуллин, Алмаз Сәгыйров, Рәмис Ситдиков (күптән түгел генә Совет Армиясе сафларына алынды) катокларны, Шәриф Галимов тырмаларны, Азат Абдрахманов, Сабир Әхсәнов, Гәрәй Галимов чәчкечләрне ремонтлыйлар.

Соңгыларына аерым туктаtaсы килә. А. Абдрахманов, Г. Галимов, С. Әхсәнов колхозда өчесе дә байтак еллар комбайнчы булып эшлиләр. Тәҗрибәлеләр, үз эшләренең осталары.

Азат Сәмигуллович Абдрахмановның улы Роберт та армиягә киткәнче комбайнда эшләп алды, икенче уллары Рәис исә авыл хуҗалыгы институтында укый, җәен «ДОН-1500» комбайны белән үз авылының кырларын иңләде. Тагын бер улы Ринат бүгенге көндә дә колхозда автомеханик булып эшли.

Гәрәй Галимовның да улы Рәмис «Нива» комбайнында эшләп, Совет Армиясе сафларына китте. Колхозда механизаторлар традициясе әнә шул рәвешчә дәвам итә.

Ремонт вакытында төрле кыенлыклар килеп чыкса да, аңардан котылу юлларын табарга тырышалар. Ике дистә елдан артык тимерче булып эшләүче Сәлих Миннехановның биредә аеруча зур өлеше керә. Бу чорда ул иң кирәкле кеше.

Механизаторлар күпчелек авыл хуҗалыгы машиналарын майлап-көйләп, алгы сызыкка куйдылар инде. Декабрь аенда алар печән җыйгыч техникаларын һәм комбайннарны ремонтларга керешәчәкләр.

**В. КАНӘФИНА.**

---

Роза Галимҗановна Хәммәдиева мәшәкатьле, зур түземлелек һәм даимилек сорый торган терлекче хезмәтен үз итте. Байтак еллардан бирле ул «Үрнәк» колхозында сыер савучы булып эшли, елның-елында әйбәт күрсәткечләргә ирешә. Быел да Роза Галимҗановна үз карамагындагы маллардан ел дәвамында 648 центнер тулай продукция җитештерергә, ягъни һәр сыердан 3600 килограмм сөт саварга булган иде. Уңган савучы аны 10 айда 852 центнер итеп үтәде, бу—һәр сыердан шул чорда 4502 шәр килограмм продукция дигән сүз. Димәк, ел дәвамына кадәр Роза Галимҗановна биш меңле чикне ашачак! Моңа реаль мөмкинлекләр дә бар. Бүген аның группасында көнлек савым 9 килограммнан артык тәшкил итә. Бу—уртача хуҗалык күрсәткеченнән шактый югары.



Рәсемдә: «Үрнәк» колхозы савучысы Р. Г. Хәммәдиева.

---

## Ишеттегезме әле...

Находка больницасының балалар тудыру бүлеге хезмәткәрләре забастовкага хәзерләнә. Алар шәһәрнең сәламәтлек саклау бүлеген бетерүне, хезмәт хакын арттыруны, социаль сфера гарантиясен киңәйтүне таләп итәләр. Медиклар, әгәр аларның таләбе канәгатьләндерелмәсә, 5 көннән кисәтү забастовкасы, ә аннан соң врачлар, шәфкать туташлары, техник хезмәткәрләр озак вакытлы забастовка ясаячакбыз, дип кисәтәләр.

x x x

Мәскәү микрорайонының 70 кә якын олы яшьтәге кешесе Теплый Стан урамы буенча транспорт хәрәкәтен берничә сәгатькә туктаттылар. Моның белән алар шәһәр читендәге кибетләрдә хәтта талонга да шикәр—аракы—шәраб әйберләре юклыкка, сәүдә кагыйдәләренең бозылуына канәгатьсезлекләрен белдерделәр.

Тик бу урынга башкаланың Көньяк-Көнбатыш префектурасы вәкилләре килгәч кенә конфликтны бастырырга туры килде. Әмма озаккамы?

x x x

Кофе яратучылар өчен авыр заманалар килде. Бу эчемлекне чит илләрдән алу өчен бездә средство беткән ахыры. Һәм менә могҗиза! «Уңган куллар» тропик продукцияне үзебезнең туфракта «игә» башлаганнар.

Кишиневта әлеге эчемлекне яратучыларга аның уникаль сортларын күпләп тәкъдим итәләр. Ул чагыштырмача арзан—килограммы 30—40 сум гына. Аны кешеләр базардан сатып алганнар. Менә хикмәт, хуш исле кофе эчәргә яраксыз булып чыккан, аны мошенниклар пласмасстан хәзерләгәннәр икән.

Әй кешеләр! Дефицит әйберләрне кулдан сатып алганда сак булыгыз! Әбит пирожныйларны паралоннан, шоколадны—оргамиттан, сырны—линолиумнан ясарга була.

x x x

Үзбәкстанның Учкудук шәһәре властьлары вак акча җитешмәү белән көрәшнең оригиналь ысулын тапканнар.

Шәһәр башлыклары аракыны бакыр һәм никель тиеннәргә ирекле сатуны оештырганнар. Халык үзенең акча янчеген чишә башлый, кыска гына вакытта кибетләрдә вак акча кытлыгы бетерелә. Моның белән бергә хәзер шәһәрнең башка службаларында тиен дефициты туачак. Чөнки шәһәр халкы металл акчалар җыярга омтылачак хәзер. Чыннан да, бәлки вак акчага автомобиль сатарлар.

x x x

Дөньяның төрле илләре—бу исәпкә Советлар Союзы һәм Кушма Штатлар да керә—БМОга 1 миллиард долларга якын бурычлы. Шулай итеп, халыкара берләшмә яңадан бөлгенлек чигенә килеп җитте.

---

● *Район Советы президиумында*

## Башкарасы эшләр бар

Халык депутатларының Октябрь район Советы президиумының соңгы утырышында беренче көн тәртибе итеп терлекчелектә югалтуларны, район агропромышленность комплексында дәүләт һәм хезмәт дисциплинасын бозуларны кисәтү һәм булдырмауга юнәлтелгән закон таләпләренең үтәлеше турында мәсьәлә куелган иде. Аның буенча информацияне авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе юрист-консульты З. М. Мәхмүтов ясады.

Утырышта билгеләп үтелгәнчә, районда югалтулар һәм хуҗасызлык күренешләре байтак. Колхоз-совхозларда малларның үлүе сәбәпле килгән зыян 9 айда 781 мең сум тәшкил итә. Бу чорда хуҗалыкларда 1495 баш мөгезле эре терлек үлә, иң зур югалтулар XXI партсъезд исемендәге, Хафизов исемендәге, «Правда», «Родина» колхозларында, «Төрнәс», «Сөлчә» совхозларында, биредә ул 160—56 баш исәпләнә.

Агымдагы елда «Россия», «Большевик», «Знамя Октября» колхозларында, «Төрнәс», «Мамык» совхозларында, дуңгызлар симертү буенча хуҗалыкара берләшмәдә күпләп дуңгызлар үлүенә юл куела. Моның төп сәбәбе итеп утырышта эшчеләрнең хезмәт вазифаларын үтәмәүләре, терлекләрне карауда технологиянең бозылуы, түбән хезмәт дисциплинасы, урта буын җитәкчеләренең үз эшләренә салкын каравы, малларның баш санына төгәл учет һәм контроль булмау күрсәтелде, аңа «Москва» колхозы, «Төрнәс» совхозы мисалында конкрет фактлар китерелде. Шунда ук малларның үлемен яшерү, терлекчелек биналарында янгын чыгу фактларының да әлеге эшкә зыяны ассызыкланды. Бүгенге көндә колхоз-совхозлар ветврачлар белән 84, зоотехниклар белән 90 процентка гына тәэмин ителгәннәр, бу район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең, хуҗалыкларның кадрлар әзерләү белән начар шөгыльләнүен күрсәтә. Утырышта шулай ук көтүне яңарту белән җитди шөгыльләнү кирәклеге дә ассызыкланды. Агымдагы елның 9 аенда Муса Җәлил исемендәге, «Родина», XXI партсъезд исемендәге, Кузнецов исемендәге колхозларда 100 сыердан бары 41—48 баш кына бозау алынган. «Восход», «Путь к коммунизму», «Знамя Октября», XXI партсъезд исемендәге колхозларда дуңгызлар, «Заветы Ильича», «Алга», XXI партсъезд исемендәге колхозда бәрәннәр алу бик начар.

Район Советы президиумы район хуҗалыклары белгечләре һәм җитәкчеләренең бу юнәлештә сүлпән эшләүләрен билгеләп, зоотехник һәм ветеринар эшне яхшырту, малларның үлем-китеменә, хуҗасызлык күренешләренә юл куймауга юнәлтелгән конкрет чаралар күрүне йөкләде. Утырышта район Советы президиумы членнарыннан тыш авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе, «Заветы Ильича», «Алга», «Чирмешән», «Знмя Октября» колхозлары, «Төрнәс» совхозы җитәкчеләре һәм белгечләре катнашты.

**«Культура бүлегенең авылда клуб учреждениеләреннән файдалану буенча эше турында».** Әлеге мәсьәлә президиум утырышына куелганчы, барлык клуб учреждениеләренең эше тикшерелде, район Советының культура, халык мәгарифе буенча даими комиссиясендә каралды. Район Советы президиумы утырышына исә авыл Советы рәисләре, авыл клублары һәм район культура бүлеге работниклары чакырылдылар. Президиум культура бүлеге мөдире Р.Х. Морадыймов информациясен тыңлап, авыл эшчәннәренә культура хезмәте күрсәтүне яхшырту, клуб учреждениеләренең материаль базасын ныгыту, кадрлар әзерләү юнәлешендә билгеле күләмдә эш алып барылуын күрсәтте. Күп кенә клублар көнкүреш йолаларын һәм бәйрәмнәрне үткәрүдә зур тәҗрибә тупладылар, 4400 ләп кеше клуб каршындагы һәртөрле түгәрәкләр, берләшмәләргә йөриләр.

Шул ук вакытта бу өлкәдә зур кимчелекләр дә яши әле. Бигрәк тә материаль база, ярлылыгы борчый. Яңа Әмзә, Абрыскино клублары иске, Салдакай, Биккол, Елаур культура йортлары яраклаштырылган бинада көн күрәләр. Мамык культура йорты төзелеше туктатылды, Кизләү, Фома, Югары Норлат, Кормыш авыл культура йортлары капиталь ремонт көтәләр. Клуб эшчәнлегендә актив формалар җитешми, район культура йортының методик кабинеты эшен тамырдан үзгәртәсе бар, тәҗрибә уртаклашу, методик ярдәм күрсәтү йомшак куелган. Президиум, әлеге кимчелекләрне күрсәтеп, каралган мәсьәлә буенча тиешле карар кабул итте.

Утырышта шулай ук перспектив характердагы һәм агымдагы башка мәсьәләләр каралды.

x x x

Шул ук көнне авыл Советы башкарма комитетлары рәисләре, хезмәт һәм сугыш ветераннарының район Советы, район потребительләр җәмгыяте, социаль-тәэминат бүлеге җитәкчеләре катнашында киңәшмә үтте. Анда Бөек Ватан һәм Әфган сугышларында катнашучыларга сәүдә хезмәте күрсәтүне яхшырту буенча өстәмә чаралар турындагы мәсьәлә каралды.

## • *Кызыклы кешеләр белән очрашу*

# „Морж“ диеп аталырга...

**Кеше организмының мөмкинлекләре без уйлаганнан күпкә зуррак. Без, табигатьнең иң ихтыярсыз балалары, баш авыртуыннан таблетка эчкәндә, тамак авыртканда компресслар белән җәфаланганда, бердәнбер балаларыбызны җылы киемнәргә урап җил-яңгырдан саклаганда, көчле рухлы, омтылышлы кешеләр үз сәламәтлекләре өчен бөтенләй башкача көрәшәләр. Берәүләр Иванов методы буенча суыкта чыныга, икенчеләр ач торып дәвалана, өченчеләре ел әйләнәсенә су коенып организмын ныгыта. Соңгыларын, мәгълүм булганча, халыкта «моржлар» дип атыйлар. Шушы көннәрдә безнең районда шундый моржларның берсе, аларның республика һәм Урта Идел буе клублары рәисе Леонид Константинович ЕРМОЛАЕВ булып, шәһәрнең икенче мәктәбе укучылары белән очрашу үткәреп китте. Без, әлбәттә, форсаттан файдаланып, аннан газета укучылар өчен берничә сүз әйтүен үтендек.**

Инде 56 яшен тутырып килүче Леонид Константинович үз яшенә хас булмаганча көр күңелле, җитез хәрәкәтле, тыныч табигатьле кеше булып чыкты. Шулай да, ни мәҗбүр иткән соң аны шулай салкында коену белән шөгыльләнергә? Бәлки бу кемнедер шаккатырырга теләп башланган шөгыльдер?

—Юк,—ди Леонид Константинович,—безнең шөгыль нәкъ менә шарлатаннарны яратмый да инде. Аның өч катгый принцибы бар: башладыңмы—өзмә, нагрузканы акрынлап үстер һәм индивидуаль сыйфатларыңны истән чыгарма.

Ә чыныга башлау әлеге дә баягы һәртөрле ялкынсыну-салкын тию авыруларыннан гарык булгач туган. 9 нчы класста укыганда салкында чыныга башлаган, авыл хуҗалыгы институтының III нче курсында укыганда «морж»лар сафына баскан. Инде аның бу өлкәдә 35 еллык стажы бар, ул республиканың иң стажлы «морж»ыннан санала. Шул еллар эчендә ул операция дә кичергән, авариягә дә юлыккан, бәхетсезлек очраклары да аз булмаган. Әмма спорт, салкында чыныгу белән шөгыльләнү нәтиҗәсендә сәламәтлеген ныгыткан. Гаиләсендә дә спортны үз итүләренә ирешкән, хатыны Иванов методы буенча салкында чыныгу ала, ике уллары — «морж»лар. Леонид Константинович хәзер республиканың иң чыныккан кешеләреннән санала. Кабан күлендә ул октябрь айларында 30—40 минут коена, километрдан ерак арага йөзә. 1989 елның 30 октябрендә Ысык Күлдә үткәрелгән марафон йөзүләрендә республикадан катнашкан 3 «морж»ның берсе нәкъ ул була. Бу хакта П.П. Моревның «Үзеңне сына» («Испытай себя») китабында бик ачык язылган, ул шәһәр китап китапханәсендә бар.

Леонид Константинович —һөнәре буенча агроном, еш кына республиканың төрле районнарында, юлда була. Әмма бу аңа 35 ел буе көндәлек режимын сакларга комачауламый. Һәр көнне коену яки салкын су бөркү, атнаның һәр пәнҗешәмбесендә ач торып организмны чистарту—бу инде аның төп яшәү рәвешенә әйләнгән. «Морж»лар клубы турында да ул мавыгып һәм горурланып сөйли. Бүген республикада 700 «морж» исәпләнә, аның 350се—Казанда. Моннан тыш Әлмәт, Лениногорск, Чаллы һәм башка шәһәрләрдә дә салкында коену белән мавыгучылар бар. Алар алдан билгеләнгән график буенча республика шәһәрләрендә үзләренең зур бәйрәмнәре —«морж»лар көнен үткәрәләр. Сүз уңаеннан, шундый бәйрәм Әлмәт шәһәрендә 19 январьда планлаштырыла. «Морж»ларның һәр очрашуы — үзенчәлекле аралашу ул. Күңел көрлеге, сәламәт көлү, шаяру, җыр-бию—аларның аерылгысыз юлдашлары.

—Аны безгә нәкъ кышкы коену, чыныгу бирә дә,—ди Леонид Константинович һәм 2 нче мәктәп укучылары алдында ясаган чыгышында да төп нәрсә итеп шуны ассызыклады: коену—ул сәламәтлек, озак яшәү, рухи көрлек.56 яшьлек «морж» бу хакта яланаяк кар өстендә баскан килеш сөйләде, ачык сулык янәшәдә булмау сәбәпле, салкын су белән коенып күрсәтте. Аннан әңгәмә спорт залында үтте. Леонид Константинович тыңлаучыларны бу шөгыльгә тартылырга чакырды, методик рекомендацияләр бирде, үз тәҗрибәсеннән чыгып киңәшләре белән уртаклашты. Әмма шуны онытырга ярамый: кеше үз мөмкинлеген һич артык бәяләргә тиеш түгел, индивидуаль мөмкинлек һәркемдә төрле. Мәктәпләр янында ачык бассейннар ясап, бу эшне җайга салганда, районда кызыксынучылар табылмый калмас иде.

—Мин ышанам: киләсе очрашуда сезнең төбәктә дә «морж»лар барлыкка килер,—диде очрашуда Леонид Константинович Ермолаев һәм аны көр тавыш белән җырлап тәмамлады:

«Морж» диеп аталырга сезне чакырам».

С. ХӘЙРУЛЛИНА.

# ТЕЛЕВИДЕНИЕ

### СИШӘМБЕ
### 3 ДЕКАБРЬ
### КАЗАН КҮРСӘТӘ

18.10 Балалар өчен. Сарман районыннан тапшыру (татар телендә).
18.40 Шигърият.
18.50 Актуаль репортаж.
19.00 Татарстан.
19.30 Телебиржа.
20.15 Әлли-бәлли-бәү.
20.30 Яшьләр иҗаты. «Кабынасы иде йолдыз булып». Актриса Гүзәл Гарапшина.
21.10 Борынгы моңнар.

### I ПРОГРАММА

6.30 Иртә.
9.05 Документаль фильм: «Пыяла дизайнеры».
9.30 Нәфис фильм: «Анна Лииса».
11.00 Балалар сәгате.
12.00 «ТЯХ».
12.10 Документаль фильм.
13.40 Телемикст.
14.25 Куен дәфтәре.
14.30 Икътисади агентлык.
15.00 «ТЯХ».
15.15 Ольга Иванова дәресләре.
15.30 Нәфис фильм: «Дон Кихот һәм Санчоның тормышы». 1 фильм. 1 нче серия.
16.55 Балалар музыка клубы.
17.35 Мультфильм.
18.00 «Фикер». Конверсия проблемалары.
18.30 «ТЯХ».
18.45 Ялта-91.
19.00 Документаль фильм.
19.25 Нәфис фильм: «Анна Лииса».
21.00 Информацион программа.
21.35 Документаль фильм.
22.40 «ТЯХ».
22.55 «Космос»та очрашулар.

### II ПРОГРАММА

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.20 Француз теле. 1 уку елы.
9.20 Мультфильмнар.
10.00 Документаль фильм.
10.20 «Рус мәдәнияты турында әңгәмәләр».
11.00 «Бишенче тәгәрмәч».
13.00 Документаль фильм.
13.30 Камера музыкасы концерты.
14.40 «Мин яраттым сезне...»
15.10 Ритмлы гимнастика.
17.00 Концерт.
17.45 «Эшкуарлык һәм традицияләр».

### ЧӘРШӘМБЕ
### 4 ДЕКАБРЬ
### КАЗАН КҮРСӘТӘ

17.20 Сәяхәтчеләр альманахы.
17.40 Телесеанс. Яшьләр программасы.
18.30 Әдәби театр. С.Сөләйманова. «Җырланмаган җырлар».
19.00 Татарстан.
19.30 Турыдан-туры элемтә. Сорауларга ТССР Халык мәгарифе министрлыгы җитәкчеләре җавап бирә.
20.30 Әлли-бәлли-бәү.
20.40 Эльфира Тимершина җырлый.

### I ПРОГРАММА

6.30 Иртә.
9.05 Документаль фильм.
9.35 Нәфис фильм: «Паром».
10.35 Мультфильмнар.
11.00 Балалар музыка клубы.
12.00 «ТЯХ».
12.10 Молдованың «Флуераш» халык музыкасы оркестры концерты.
13.50 Биржа яңалыклары.
14.05 Куен дәфтәре.
14.10 Партнер.
14.40 Сәүдә рәте.
15.00 «ТЯХ».
15.15 Бүген һәм шул чакта.
15.45 «Дон Кихот һәм Санчоның тормышы». 1 фильм. 2 нче серия.
16.55 Балалар сәгате.
17.55 Һәвәсләр дөньясы.
18.10 Телефильм: «Пластилин».
18.30 «ТЯХ».
18.45 Киләчәк турында хатирә.
19.30 Документаль фильм.
19.55 Нәфис фильм. «Паром».
21.00 Информацион программа.

### II ПРОГРАММ

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 Немец теле. 1 уку елы.
8.45 Немец теле. 2 уку елы.
9.15 «Менеджерлар мәктәбе».
9.45 Мультфильм.
10.05 Н. Лесков.
11.00 З. Гердт чакыра.
11.45 «Фольклор». Билгесез мәдәниятлар.
13.00 Чын гүзәллек сәнгате.
13.30 Эстрада көзгесендә. М. Муромов.
14.10 «Шигърият».
14.55 Документаль фильм.
17.00 «Радуница» ансамбле чыгышы.
17.15 «Эрудитлар өчен күнегү».
17.45 «Менеджерлар мәктәбе».
18.15 «Очрашудан соң очрашу».




**Киекле авылында яшәүче кадерле әниебез һәм зур әниебез ГӨЛСИРӘ ФАТЫЙХ кызы НОГМАНОВАны 50 яшьлек юбилее белән кайнар котлыйбыз. Аңа исәнлек, саулык, шатлык һәм бәхет, эти белән тигез гомер итүләрен телибез.**

**БАЛАЛАРЫ, ОНЫКЛАРЫ.**

## БЕЛДЕРҮЛӘР

Татпотребсоюзның Норлат-Октябрь районара базасына каклау цехында эшләү өчен кочегар, җыештыручы кирәк.

## «НОРЛАТ СӘҮДӘ ЙОРТЫ» ФИРМАСЫ

ЭШМӘКӘРЛӘРНЕ БЕЗНЕҢ БЕЛӘН ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ИТӘРГӘ ЧАКЫРА.

БЕЗ СЕЗНЕҢ ЭЧКЕ ҺӘМ ТЫШКЫ БАЗАРДА САТЫП АЛУ, САТУ СФЕРАСЫНДА ФАЙДАЛЫ ПАРТНЕРЛАР ЭЗЛӘҮДӘ ВАКЫТЫГЫЗНЫ ҺӘМ ФИНАНСЫГЫЗНЫ ЭКОНОМИЯЛИ АЛАБЫЗ.

*Безнең адрес: Совет урамы, 117*
*Телефоннар: 2-14-69, 2-15-96.*

«Кондырча» колхозы идарәсе, профсоюз комитеты элекке ферма мөдире ЯКУБ ИМАМЕТДИН улы ТАҖИЕВның вакытсыз вафат булуын тирән кайгы белән белдерә һәм мәрхүмнең гаиләсенең, якыннарының авыр хәсрәтен уртаклаша.

«Кондырча» колхозы ферма коллективы элекке мөдирләре ЯКУБ ИМАМЕТДИН улы ТАҖИЕВның вакытсыз үлүе сәбәпле аның гаиләсенең, туганнары һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклаша.

**МӨХӘРРИР Ә. У. АБДУЛЛИН.**

**Учредитель: халык депутатларының Октябрь район Советы.**

**Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.**

**РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.**
**ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге—2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.**

**Газетаны Фидания ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Римма ГАНИЕВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор Зөлфия ВӘЛИЕВА.**

**«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**ТССР информация һәм матбугат Министрлыгының Норлат-Октябрь типографиясе.**

**Күләме—1 басма табак.** Заказ 145. Тираж 3413.